ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Региональ салымнар суммалары өлешендә бурычны түләттерү ышанычсыз булуны тануга өстәмә нигезләр билгеләү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2024 елның 29 мартында
кабул ителде

1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

Әлеге Закон Россия Федерациясе Салым кодексының 59 статьясындагы 3 пункты нигезендә региональ салымнар суммалары өлешендә бурычны түләттерү ышанычсыз булуны тануга өстәмә нигезләр билгели.

2 статья. **Региональ салымнар суммалары өлешендә бурычны түләттерү ышанычсыз булуны тануга өстәмә нигезләр**

2024 елның 1 гыйнварына аерым салым түләүчеләргә исәпләнелә торган, түбәндәге нигезләр буенча түләү һәм (яисә) түләттерү мөмкин булмаган региональ салымнар суммалары өлешендәге бурыч түләнүгә ышанычсыз дип таныла:

1) варислар мираска хокуктан баш тарткан, варислар булмаган яисә мирас ачылган көннән бер ел дәвамында мирас кабул итеп алынмаган очракта, вафат булган яисә вафат булган дип игълан ителгән физик затларның бурычы булу;

2) 2024 елның 1 гыйнварына кадәр юкка чыгарылган региональ салымнар буенча оешмаларга яисә индивидуаль эшкуарларга исәпләнелә торган бурыч булу;

3) Россия Федерациясе Салым кодексының 48 статьясында билгеләнгән сроклар тәмамланганнан соң физик затларның 500 сумнан артмаган суммада бурычы булу.

3 статья. **Региональ салымнар суммалары өлешендә бурычны түләттерү ышанычсыз булуны тануга өстәмә нигезләр барлыгын раслаучы документлар**

Региональ салымнар суммалары өлешендә бурычны түләттерү ышанычсыз булуны тануга өстәмә нигезләр барлыгын раслаучы документлар:

1) әлеге Законның 2 статьясындагы 1 пунктында күрсәтелгән нигез булганда:

а) бурыч суммасы турында физик затның яшәү урыны буенча салым органы белешмәсе;

б) вафат булуга бәйле рәвештә, физик затны салым органнарында исәптән алу хакындагы белешмәләр;

в) мираска хокук турында таныклык бирү хакындагы белешмәләрнең булмавы турында салым органы белешмәсе;

2) әлеге Законның 2 статьясындагы 2 пунктында күрсәтелгән нигез булганда:

а) бурыч суммасы хакында оешманы, индивидуаль эшкуарны, индивидуаль эшкуар статусын югалткан физик затны исәпкә алу урыны буенча салым органы белешмәсе;

б) салымны юкка чыгаруга нигез булган норматив хокукый акт турындагы белешмәләр (исеме, датасы, номеры);

3) әлеге Законның 2 статьясындагы 3 пунктында күрсәтелгән нигез булганда – 500 сумнан артмаган суммада бурыч булу хакында салым органы белешмәсе.

4 статья. **«Региональ салымнар буенча недоимка, пенялар һәм штрафлар буенча бурыч түләнүгә ышанычсызлыкны тануга өстәмә нигезләр билгеләү турында» Татарстан Республикасы Законын үз көчен югалткан дип тану**

«Региональ салымнар буенча недоимка, пенялар һәм штрафлар буенча бурыч түләнүгә ышанычсызлыкны тануга өстәмә нигезләр билгеләү турында» 2017 елның 19 июлендәге 54-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 55 (I өлеш) үз көчен югалткан дип танырга.

5 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2024 ел, 12 апрель
№ 18-ТРЗ